ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.10.2020 с.Старое Дрожжаное № 558

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Татар Бизнәсе башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 23.08.2018 ел, № 472 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен «Татар Бизнәсе башлангыч мәктәбе-балалар бакчасы» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставына, 3.3 пунктны түбәндәге яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.3. Учреждениедә белем бирү эшчәнлеге Россия Федерациясе дәүләт телендә алып барыла.

Россия Федерациясе гражданнары Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телдә башлангыч гомуми һәм төп гомуми белем алуга, шулай ук мәгариф системасы бирә торган мөмкинлекләр чикләрендә Россия Федерациясе халыклары телләре арасыннан туган телне өйрәнү хокукына ия. Россия Федерациясе халыклары телләре, шул исәптән рус теле буларак, дәүләт аккредитациясе алган белем бирү программалары кысаларында туган телне укыту һәм өйрәнү федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет Җитәкчесе: Д. Ә. Сатдинов